| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬ-<br>НЫЙ РАЙОН<br>СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР<br>422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙ-<br>ОНЫ<br>КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ<br>422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15 |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 19 апреленнән № 10

Кукмара поселок Советының 2012 елның 12 июлендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1.«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2012 елның 12 июлендәге 14 номерлы карары белән расланган Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә (2016 елның 30 сентябрендәге 26 номерлы, 2019 елның 18 февралендәге 3 номерлы, 2019 елның 07 августындагы 17 номерлы үзгәрешләр редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

18.1 статьясында – Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләмнәре – 1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- индивидуаль торак төзелеше өчен – 0,1 га.».

2. Әлеге карарны Кукмара муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Кукмара шәһәре Мэры С.Д.Димитриев